**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.11.2016 Балык Бистәсе штп. № 169пи

2017 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең нормативларын раслау турында

“Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе тәкъдимен карап, “Россия Федерациясендә мәгариф турында” 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 99 статьясына, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пунктына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Мәктәпләрдә укучыларны йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары турында” 2010 елның 6 декабрендәге 1013 номерлы, “Балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын йөртүне оештыруны финанслау нормативларын хисаплап чыгару буенча Методик тәкъдимнәрне раслау турында" 2010 елның 5 июлендәге 545 номерлы карарларына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына туры китереп КАРАР БИРӘМ:

1.Расларга:

-2017 елга Балык Бистәсе муниципаль районында балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең нормативларын;

2.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына гомуми белем бирү оешмаларын, әлеге карарның 1 пункты белән расланган балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмалары укучыларын

йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең нормативларына туры китереп, финанслауны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

Җитәкче вазифаларын башкаручы Д.Ә. Низамов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
2016 елның 10 октябрендәге
169 пи номерлы карары белән
расланган

2017 елга балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең нормативлары

| Автотранспорт чарасы моделе атамасы | Ике ставкалы норматив күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасына ставка, бер елга сумнарда | Автотранспорт чарасының бер километр юл узуга ставкасы, сумнарда |
| КАВЗ | 103980 | 33,53 |
| ПАЗ | 104238 | 33,52 |
| ГАЗ «Газель» | 98836 | 28,22 |
| УАЗ | 98383 | 27,10 |
| FIAT | 98125 | 26,10 |
| Peugeot Boxer | 98640 | 25,73 |
| Ford Transit | 99464 | 28,11 |